| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«УРМЫШЛИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ<br>ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«УРМЫШЛЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 20 марты № 8

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы “Урмышлы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 1 августындагы 19 номерлы карары белән расланган Лениногорск муниципаль районының "Урмышлы авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәткәрләрне коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәт алу тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының " Урмышлы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы “Урмышлы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 1 августындагы 19 номерлы карары белән расланган Лениногорск муниципаль районының "Урмышлы авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәткәрләрне коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәт алу тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 пунктта «бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативы» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

3. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Урмышлы авыл җирлегендә урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка хәбәр итәргә,

Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (leninogorsk.tatar.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районының
«Урмышлы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы А.Ф. Хәбибуллин